| | |
|---|---|
| ГЛАВА МАКУЛОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЮГАРЫ ОСЛАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ<br>МАКЫЛ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.10.2022 с. Русское Макулово 05

Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Татар Макылы авылы гражданнарының үзара салым акчаларын кертү һәм һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче статьясына, Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 19 ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2023 елда Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең Татар Макылы авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлдерү белән килешәсезме:

- Татар Макылы авылы зиратының керү төркеме каршында тукталыш мәйданын һәм аңа керү юлын бетонлау.

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Мәчет бинасы янында түбәндәге адрес буенча халык җыенын уздырырга: Татар Макыы авылы, Үзәк урамы, 169 йорт 11.00 сәгатьтә.
4. Макыл авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны «Волжская новь» район газетасында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырырга, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районының
Макыл авыл җирлеге башлыгы урынбасары П.Е Карпухин